ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Постановление Карар

20.06.2023 г.Чистополь № 369

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 20 февралендәге “2021-2023 елларга
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында
физик культура һәм спортны үстерү”
муниципаль программасын раслау турында»гы
93 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында»гы 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 2377-р номерлы, 2021 елның 20 гыйнварындагы 68-р номерлы, 2022 елның 29 апрелендәге 877-р номерлы боерыкларына нигеләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 93 номерлы карары белән расланган “2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү” муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 2 нче кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарның 1 нче кушымтасына нигезләнеп бәян итәргә.
1.2 3 нче кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарның 2 нче кушымтасына нигезләнеп бәян итәргә.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләнә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының __________елгы
_________номерлы  карарына
1 нче кушымта

“Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының 20.02.2021 елгы
93 номерлы  карарына
2 нче кушымта

2023 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | ел дәвамында | 544,91 |
| 2 | Спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | ел дәвамында | 63,00 |
| 3 | Югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүләр | ел дәвамында | 3400,00 |
| 4 | Спорт әзерлеге буенча программаларны гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында, хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында катнашуы | ел дәвамында | 356,30 |
| 5 | Физик культура, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру белән бәйле чараларны гамәлгә ашыру, әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре алуга бәйле рәвештә физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль биремне үтәвен финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә. | ел дәвамында | 109,05». |

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының __________елгы
_________номерлы карарына
1 нче кушымта

“Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының 20.02.2021 елгы
93 номерлы карарына
3 нче кушымта

2023 елга җирле бюджет акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Физик культура, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру белән бәйле чараларны гамәлгә ашыру, әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре алуга бәйле рәвештә физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль биремне үтәвен финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә. | ел дәвамында | 1,09». |